**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы**
**Мәдәният һәм сәнгать буенча совет турында**

Республика дәүләт мәдәни сәясәтен нәтиҗәле гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча советны оештырырга.

2. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча совет турында нигезләмәне (1 нче кушымта) һәм аның составын (2 нче кушымта) расларга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 29 гыйнвар
№ ПУ-40

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «29» гыйнварындагы
ПУ-40 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча совет турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать буенча совет (алга таба – Совет) Татарстан Республикасы Президентына мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге вазгыять турында мәгълүмат бирү, Татарстан Республикасы Президентының мәдәният һәм сәнгать оешмалары һәм иҗатчылар белән хезмәттәшлеген тәэмин итү, республика дәүләт мәдәни сәясәтенең актуаль мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү өчен оештырылган даими эшләүче эксперт-консультатив киңәшмә орган булып тора.

1.2. Совет Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эшчәнлек алып бара.

## II. Советның бурычлары

2.1. Советның төп бурычлары түбәндәгеләр:

республика дәүләт мәдәни сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү һәм аны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән чаралар эшләү буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү;

мәдәният өлкәсендә Татарстан Республикасы Президентына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә торган тәкъдимнәрне һәм норматив-хокукый актлар проектларын, аларны гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәр эшләү өчен, карап тикшерү;

Татарстан Республикасы Президентына милли мәдәният өлкәсендә вазгыять турында даими рәвештә мәгълүмат бирү;

дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының мәдәният оешмалары, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә эксперт җәмәгатьчелек, иҗтимагый берләшмәләр, иҗат һәм фән интеллигенциясе вәкилләре белән хезмәттәшлек мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр әзерләү.

## III. Советның хокуклары

3.1. Совет түбәндәгеләргә хокуклы:

компетенцияләре чикләрендә федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук дәүләт, иҗтимагый һәм башка оешмалардан билгеләнгән тәртиптә кирәкле материалларны соратып алырга;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнары белгечләрен, дәүләт, иҗтимагый һәм башка оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен билгеләнгән тәртиптә Совет эшенә җәлеп итәргә;

Совет карап тикшерә торган мәсьәләләр буенча материаллар әзерләү өчен үзенең эшчәнлеге юнәлешләре буенча эш төркемнәре оештырырга.

## IV. Советның составы һәм аның эшчәнлеген оештыру

4.1. Совет рәис, аның урынбасары, секретарь һәм Совет әгъзаларыннан формалаштырыла.

Совет әгъзалары җәмәгать башлангычларында эшли.

4.2. Совет рәисе:

Совет эшенә җитәкчелек итә;

Совет утырышларында рәислек итә;

Совет кабул иткән карарларны раслый.

4.3. Совет рәисе урынбасары, Совет рәисе булмаганда, аның кушуы буенча Совет эшенә җитәкчелек итә һәм Совет утырышларында рәислек итә.

4.4. Совет секретаре:

Совет утырышларын әзерләүне координацияләүне башкара;

Совет утырышларына материалларны, шулай ук аның карарларының проектларын әзерләүне оештыра;

Совет рәисенә Советта эшләр барышы турында мәгълүмат бирә.

4.5. Совет рәисе булып Татарстан Республикасы Президенты, Совет рәисе урынбасары булып Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе тора.

4.6. Совет үз эшчәнлеген Совет рәисе раслаган эш планы нигезендә алып бара.

4.7. Советның үз атамасы язылган бланкы бар. Советның эшчәнлегенә кагылышлы язышу барышында хатларны рәис урынбасары имзалый.

4.8. Совет эшчәнлегенең агымдагы мәсьәләләрен хәл итү өчен Совет рәисе урынбасары, секретарь һәм Советның аерым әгъзаларыннан торган

президиум булдырыла. Президиумның персональ составы һәм андагы әгъзаларның саны Совет тарафыннан билгеләнә.

4.9. Совет президиумы:

Совет утырышларында карап тикшерү өчен мәсьәләләр тәкъдим итә;

кварталга кимендә бер тапкыр җыела;

оешмаларны, шулай ук галим һәм белгечләрне мәгълүмати-аналитик һәм эксперт эшләрен башкаруга җәлеп итү белән бәйле оештыру мәсьәләләрен һәм башка мәсьәләләрне хәл итә.

4.10. Совет президиумы карары беркетмә белән рәсмиләштерә, аңа утырышта рәислек иткән президиум әгъзасы кул куя.

4.11. Совет утырышлары елына кимендә ике тапкыр үткәрелә.

Совет утырышын Совет рәисе яки аның кушуы буенча Совет рәисе урынбасары үткәрә.

Совет әгъзаларының яртысыннан күбрәге катнашкан очракта, Совет утырышы гамәлгә хокуклы дип санала.

Советның карарлары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Совет әгъзаларының күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Советның Совет секретаре тарафыннан кул куелган карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырыш уздырылган датадан җиде эш көненнән дә соңга калмыйча, утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана.

4.12. Советның эшчәнлеген оештыру мәсьәләләренә кагылышлы карарлар кабул иткәндә, Совет әгъзаларының сораштыру кәгазьләре кулланып тавыш бирү мөмкинлеге бар.

4.13. Советның эшчәнлеген оештыруны һәм матди-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы башкара.

---

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «29» гыйнварындагы
ПУ-40 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты каршындагы
Мәдәният һәм сәнгать буенча совет составы**

| | |
|---|---|
| Миңнеханов<br>Рөстәм Нургали улы | Татарстан Республикасы Президенты, Совет рәисе |
| Сәфәров<br>Әсгать Әхмәт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары |
| Әюпова<br>Ирада Хафизҗан кызы | Татарстан Республикасы мәдәният министры, Совет секретаре |
| Александровская<br>Ирина Алексеевна | Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәдәният мәсьәләләре буенча комиссиясе рәисе урынбасары, «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Әхиярова<br>Резедә Зәки кызы | Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты, композитор, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (килешү буенча) |
| Әхмәдиева<br>Роза Шәйхәйдәр кызы | Казан дәүләт мәдәният институты ректоры вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча) |
| Барыкин<br>Алексей Александрович | кинорежиссер (килешү буенча) |
| Батуллин<br>Нурбәк Роберт улы | хореограф, биюче (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Бикчәнтәев<br>Фәрит Рәфкать улы | Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры (килешү буенча) |
| Бикчәнтәев<br>Дмитрий Андреевич | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, композитор, автор-башкаручы (килешү буенча) |
| Вәлиев<br>Разил Исмәгыйль улы | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татар «ПЕН-үзәге» – Татарстан Республикасы язучыларының татар әдәбиятын саклап калу, үстерү һәм популярлаштыру буенча төбәк иҗтимагый оешмасы президенты, «Җыен» фонды идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиева-Сөләйманова<br>Гүзәл Фоат кызы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты баш фәнни хезмәткәре (килешү буенча) |
| Гаффаров<br>Ильяс Марат улы | Yummy Music музыкаль лейблына нигез салучы (килешү буенча) |
| Диамантэ<br>Армандо Луиджиевич | «Мастеровые» рус драма театры директоры (килешү буенча) |
| Завьялова<br>Ирина Васильевна | Татарстан Республикасы Милли музее филиалы – Е.А. Боратынский музее мөдире (килешү буенча) |
| Зәйдуллин<br>Ркаил Рафаил улы | Татарстан Республикасының халык шагыйре, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Зәйниев<br>Илгиз Газинур улы | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, драматург, «Әкият» татар дәүләт курчак театры баш режиссеры (килешү буенча) |
| Ибәтуллина<br>Ирина Петровна | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Үзәкләштерелгән район клуб системасы директоры (килешү буенча) |
| Измайлова<br>Светлана Владимировна | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Халыклар дуслыгы йорты режиссеры, Казан шәһәренең «Русская песня» халык хоры җитәкчесе (килешү буенча) |
| Клюкина<br>Инесса Арутюновна | «Э-моция» иҗат инклюзив студиясе» автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |
| Манько<br>Екатерина Олеговна | Татарстан Республикасында «Россия рәссамнары иҗат берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасының яшьләр секциясе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөхәмммәтҗанов<br>Рәүфәл Сабир улы | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры директоры (килешү буенча) |
| Нәбиуллина<br>Карина Рәшит кызы | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының архитектура һәм дизайн институты директоры, икътисад фәннәре кандидаты (килешү буенча) |
| Нәфыйгова<br>Альбина Хәкимҗан кызы | «Время кино» кинопроектларга булышлык итү һәм фестивальләр оештыру буенча автоном коммерциячел булмаган оешмасы директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Низамов Эльмир Җәүдәт улы | композитор (килешү буенча) |
| Понедельникова Наталья Геннадьевна | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Тәтешнең туган як тарихы музее директоры (килешү буенча) |
| Руденко Гөлзадә Рәкыйп кызы | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендә премиясе лауреаты, Алабуга дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы генераль директоры (килешү буенча) |
| Ситдыйков Айрат Габит улы | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты директоры, тарих фәннәре докторы (килешү буенча) |
| Славутский Александр Яковлевич | Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстан Республикасының халык артисты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Федор Волков исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры сәнгать җитәкчесе – директоры (килешү буенча) |
| Сладковский Александр Витальевич | Россия Федерациясенең халык артисты, Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры сәнгать җитәкчесе – баш дирижеры (килешү буенча) |
| Телешева Ирина Анатольевна | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Аксубай авылара үзәк китапханәсе директоры (килешү буенча) |
| Фәттахов Рифат Әхмәт улы | Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасының Рәшит Ваһапов исемендәге татар мәдәнияте иҗтимагый фонды директоры (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Фәтхетдинов<br>Салават Зәки улы | Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, җырчы (килешү буенча) |
| Хөснетдинов<br>Зиннур Зыятдин улы | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, язучы, «Сәхнә» мәдәният һәм сәнгать журналы баш мөхәррире (килешү буенча) |
| Шәрәфиев<br>Равил Шаһап улы | РСФСРның халык артисты, Татарстан АССРның халык артисты, Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры драма артисты (килешү буенча) |
| Шарова<br>Луиза Николаевна | язучы, Татар китабы йорты директоры (килешү буенча) |
| Эйдинов<br>Григорий Львович | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (килешү буенча) |
| Яркова<br>Инна Игоревна | «Живой город» заманча сәнгатькә ярдәм күрсәтү фонды директоры (килешү буенча) |